РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕНЫРТИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422063, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Б.Нырты, ул. М Джалиля, д.13
тел. (84362) 45-2-32

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422063, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Нырты авылы, М Җәлил урамы, 13 йорт
тел. (84362) 45-2-32

e-mail: Bnir.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

17.02.2023 — №7

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының 2021 елның 29 сентябрендә кабул ителгән №19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Саба районы Прокуратурасының 09.02.2023 №02-08-02-2023/198-23-20920031 протесты һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 04.11.2022 №427-ФЗ Федераль законның «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 26.12.2008 елгы №294-ФЗ Федераль законның 14, 18 статьяларына (алга таба Закон), Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе турында» 04.02.2023 №УП-68 Указына таянып, Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының 29.09.2021 елны №19 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында” Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге чикләрендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.9.1. пунктының 5) пунктчасында «Президент» сүзен Башлык (Рәис) сүзенә алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 1.9. пунктының 13) пунктчасын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«13) Җитәкче, бүтән вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының, муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тикшерелергә тиешле затларны административ регламентлар яисә контроль чараларын үткәрүне җайга сала торган башка норматив хокукый актлар һәм юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген башкарганда файдаланыла торган объектларда уздыру тәртибе белән таныштырырга тиеш.»;

1.3. Нигезләмәнең 5.11. пунктының 5.11.1. пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге өченче абзац белән тулыландырырга:

«Күчмә тикшерү үткәрелә башлаганчы, юридик затның бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча, аларны административ регламент яисә башка норматив хокукый акт (шундый административ регламент яки башка норматив хокукый акт булганда) нигезләмәләре белән таныштыру, шулар нигезендә тикшерү үткәрелгәндә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/nirti адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олы Нырты авыл җирлеге башлыгы Р.З.Сәфәргалиев